**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘБДЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

**дүртенче чакырылышның унынчы утырышы**

**13 ноябрь 2021 ел** **№47** **Әбде авылы**

**Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге советының «Дәүләт милке чикләнмәгән Әбде авыл җирлеге муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында.**

«Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына линияле объектларны урнаштыруны гадиләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 августындагы 341-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге советының «Дәүләт милке чикләнмәгән Әбде авыл җирлеге муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Әбде авыл җирлегенең муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турында нигезләмәнең 12.1 пунктында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм эш итү тәртибе хакында "сервитут" сүзләреннән соң, "гавами сервитут" сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә халыкка җиткерергә.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Әбде авыл җирлеге башлыгы: Н.Р.Рахматуллин